**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ**
**И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ**
**РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_10.09.2021_ ___977-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суыртү станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары проектын раслау турында» 2016 елның 18 апрелендәге 327-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суыртү станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары проектын раслау турында» 2016 елның 18 апрелендәге 327-п номерлы боерыгына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2021 елның 10 сентябрендәге
977-п номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары проектын раслау турында» 2016 елның 18 апрелендәге 327-п номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерык атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрен билгеләү турында;

Боерыкның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 30 ноябрендәге 1316-п номерлы боерыгы нигезендә, 2015 елның 22 сентябрендәге Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалануга ТАТ БУА № 01441 ВЭ лицензиясен, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү турында 2011 елның 1 декабрендәге № 16.11.11.000.Т.001542.12.11санитар-эпидемиология бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук тәкъдим ителгән Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суыртып агызу станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналарын проекты нигезендә боерык бирәм:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланган «Су белән тәэмин итү һәм эчә торган су үткәргечләрене чыганакларының санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә әлеге боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суыртып агызу станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналарын, әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә территориядән хуҗалыкта файдалану режимы белән билгеләргә.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Транснефть-Прикамье» АҖ;

- «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФБУ филиалына, – санитар саклык зонасын билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләр буенча чаралар уздыруны тәкъдим итәргә:

- Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләре, су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендәге территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимнары турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештыру турында;

- территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә санитар саклык зоналарын билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру турында»;

боерыкның 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтада:

1 бүлектәге 1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган урыннарда урнашкан, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен, аларны чыгарганда су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 3 бүлек өстәргә:

«3. Икенче пояс буенча чаралар

2 нче бүлектә күрсәтелгән чаралардан тыш, җир асты су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарындагы икенче пояс чикләрендә түбәндәге

өстәмә чаралар үтәлергә тиеш:

3.1. Рөхсәт ителми:

зиратлар, үләт базлары, урыннарда санитария шартларын яхшырту кырлары, фильтрлаштыру кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм җир асты суларын микроб белән пычрату куркынычы тудырган башка объектларны урнаштыру;

ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;

төп кулланудагы урманнарны кисү һәм үзгәртеп кору.

3.2. Торак пунктлар һәм башка объектлар территорияләрен санитар төзекләндерү чараларын үтәү (канализация белән тәэмин итү, су үткәрми торган ташландык су чокыры ясау, өслек суларын читкә агызуны оештыру һ.б.)».

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 18 апрелендәге 327-п номерлы боерыгына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 10 сентябрендәге 977-п номерлы боерыгы редакциясендә)

**Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналарының беренче поясы чикләре**

Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү һәм җитештерүне су белән тәэмин итү максатында җир астыннан су алу өчен кулланыла торган җир асты байлыклары кишәрлеге Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу торак пунктыннан көнбатышка таба 1,0 км урнашкан.

Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасы өч скважинадан тора: икесе (№№1,2) эшли һәм берсе (№3) консервацияләнгән.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

№ 1 скважина - төньяк киңлектә: $54^0 53'21,1''$, көнчыгыш озынлыкта: $48^0 12'58,0''$;

№ 2 скважина - төньяк киңлектә: $54^0 53'28,1''$, көнчыгыш озынлыкта: $48^0 12'58,1''$;

№ 3 скважина - төньяк киңлектә: $54^0 53'25,4''$; көнчыгыш озынлыкта: $48^0 13'09''$.

№№1,2 скважиналар арасындагы аралык – 210,0 метр, №№2,3 скважиналар арасында – 199,5 метр, №№1,3 скважиналар арасында – 240,0 метр.

Санитар саклык зонасының беренче поясы астындагы җир кишәрлекләренең кадастр номерлары:

№ 1 скважина: 16:14:140104:25;

№ 2 скважина: 16:14:140104:27;

№ 3 скважина: 16:14:140104:23.

Беренче поястагы санитар саклык зонасы (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ

филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналарының беренче поясы чикләре гамәлдәге коймалар чикләрендә: скважина авызыннан 30 метрлы радиус белән билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы.

Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналарының икенче поясы чикләре скважина авызыннан 50,0 метрлы радиус белән билгеләнә.

Санитар саклык зонасының III поясы.

Казан Район нефть үткәрү идарәсенең («Транснефть - Прикамье» АҖ филиалы) «Суыксу» нефть суырту станциясендә җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләре скважина авызыннан 354,0 метрлы радиус белән билгеләнә.

Министр урынбасары
И.И. Гобәйдуллин ________________________________

Минерал-чимал һәм су ресурслары
идарәсе җитәкчесе
А.М. Чинарев ________________________________

Хокукый тәэминат бүлеге җитәкчесе
А.И. Ткачук ________________________________

Каты файдалы казылмалар
геологиясе бүлеге җитәкчесе
С.А. Шутникова ________________________________